СОВЕТ СТЕПНОШЕНТАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КЫР ШОНТАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Кыр Шонталы авылы

05.07.2022 № 27

**Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлеге Советының 07.04.2016 №24 нче «Кыр Шонталы авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгәдәгъ вакылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр, шулайук муниципаль берәмлектә муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы» карарына үзгәрешләр кертү турында (16.11.2018 ел №81, 28.06.2021ел №17 дәге үзгәрешләр белән.)**

«Россия Федерациясенеңаерым закон актларынаүзгәрешләркертүтурында» 01.04.2022 ел, № 90-ФЗ Федераль закон кабул ителүгәбәйлерәвештә, «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турындаһәм Россия Федерациясенеңаерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыручаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указы нигезендә,

**Кыр Шонталы авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Кыр Шонталы авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук Кыр Шонталы авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлеге Советының 2016 елның 7 апрелендәге 24 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, 8 пунктның 3 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«3) үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеген, башка күчемсез мөлкәт объектын, транспорт чарасын,

кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активларын, цифрлы валютаны хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр), әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганга кадәрге соңгы өч елдагы гомуми керемennән, алыш-биреш башкарылган алыш-биреш чыганакларыннан артып китсә.».

1. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Кыр Шонталы авыл җирлеге башлыгы** **Ф.Я.Хамадеев**